**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2026 елның 20 июлендәге 2543 номерлы карары**

**Казан шәһәрендә триатлон буенча Татарстан Республикасы чемпионатын, акватлон буенча Казан шәһәре чемпионатын һәм беренчелеген, «Казан триатлоны – 2026» республика ярышларын уздыру һәм чараларны әзерләү һәм үткәрү чорында транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләү турында**

1995 елның 10 декабрендәге 196-ФЗ номерлы «Юл хәрәкәте иминлеге турында»гы, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы, 2007 елның 8 ноябрендәге 257-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында»гы федераль законнарга һәм 2009 елның 3 августындагы 43-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында»гы Татарстан Республикасы законына таянып, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 5 мартындагы 159 номерлы «“Татарстан Республикасында физик культураны һәм спортны үстерү” Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында»гы карары нигезендә, сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау, халыкны физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүгә җәлеп итү, Казан шәһәрендә триатлонны популярлаштыру максатыннан:

1. **Карар бирәм**:

1.1. Казан шәһәрендә триатлон буенча Татарстан Республикасы чемпионатын, акватлон буенча Казан шәһәре чемпионатын һәм беренчелеген, «Казан триатлоны – 2026» республика ярышларын әзерләү һәм уздыру вакытына әлеге карарга 1-4 кушымталар нигезендә транспорт чаралары хәрәкәтенә чикләү кертергә:

1.1.1. 2026 елның 22 июлендә 00:00 сәгатьтән 2026 елның 26 июлендә 23:30 сәгатькә кадәр Игенчеләр Сарае янында парковкада;

1.1.2. 2026 елның 26 июлендә 03:30 сәгатьтән 16:15 сәгатькә кадәр «Миллениум» күперендә һәм Вишневский урамында (С.Хәким урамыннан

Вишневский урамыннан  Н.Ершов урамына чыгу юнәлешендә, хәрәкәтнең ике уң полосасын чикләү);

1.1.3. 2026 елның 26 июлендә 03:30 сәгатьтән 16:15 сәгатькә кадәр «Миллениум» күпере астындагы юл буйлап («Миллениум» күпереннән А.Козин урамына кадәр ике юнәлештә дә хәрәкәтне туктатып тору);

1.1.4. 2026 елның 26 июлендә 03:30 сәгатьттән 16:00 сәгатькә кадәр «Миллениум» күпере астындагы юл буйлап (Вишневский урамыннан Подлужная урамына кадәр ике як юнәлеш буенча чыгу юлларында ике юнәлештә дә хәрәкәтне туктатып тору);

1.1.5. 2026 елның 26 июлендә 03:30 сәгатьтән 16:15 сәгатькә кадәр Вишневский урамы буйлап («Миллениум» күпереннән Н.Ершов урамына чыгу юнәлешендә ике юнәлештә дә хәрәкәтне туктатып тору);

1.1.6. 2026 елның 26 июлендә 03:30 сәгатьтән 16:15 сәгатькә кадәр Н.Ершов урамы буйлап (Вишневский урамыннан чыгу юлыннан алып К.Маркс урамына кадәр, «Корстон» сәүдә-күңел ачу комплексы территориясенә үтәли чыгу (кирәк булганда) һәм электр җир өсте транспорты йөрү мөмкинлеге белән хәрәкәтнең уң яктагы бер ярым хәрәкәт полосасын чикләү);

1.1.7. 2026 елның 26 июлендә 03:30 сәгатьтән 16:15 сәгатькә кадәр К.Маркс урамы буйлап (Н.Ершов урамыннан Толстой урамына кадәр, электр җир өсте транспорты йөрү мөмкинлеге белән уң яктагы бер ярым хәрәкәт полосасын чикләү);

1.1.8. 2026 елның 26 июлендә 03:30 сәгатьтән 16:15 сәгатькә кадәр Толстой урамы буйлап (К.Маркс урамыннан Большая Красная урамына кадәр ике юнәлештә дә хәрәкәтне туктатып тору);

1.1.9. 2026 елның 26 июлендә 03:30 сәгатьтә 16:15 сәгатькә кадәр Большая Красная урамы буенча (Толстой урамыннан Батурин урамына кадәр, Жуковский һәм Япеев урамнары ягыннан үтәли чыгу мөмкинлеге белән хәрәкәт юнәлешен туктатып тору);

1.1.10. 2026 елның 26 июлендә 03:30 сәгатьтә 16:15 сәгатькә кадәр Батурин урамы буйлап (Большая Красная урамыннан Кремль яр буе урамына кадәр ике юнәлештә дә хәрәкәтне туктатып тору);

1.1.11. 2026 елның 26 июлендә 03:30 сәгатьтән 16:15 сәгатькә кадәр Кремль яр буе урамы буенча (Мәңгеллык мәйданына чыгу юлыннан Батурин урамына кадәр хәрәкәтнең бер юнәлешен туктатып тору);

1.1.12. 2026 елның 26 июлендә 03:30 сәгатьтән 16:15 сәгатькә кадәр автомобиль юлы буйлап (Мәңгеллык мәйданы) (Батурин урамына Ташаяк урамыннан чыгу юлында хәрәкәтнең бер юнәлешен туктатып тору);

1.1.13. 2026 елның 26 июлендә 03:30 сәгатьтән 16:15 сәгатькә кадәр Кремль дамбасы буйлап (Батурин урамыннан алып С.Хәким урамына кадәр,

электр җир өсте транспорты йөрү мөмкинлеге белән уң яктагы бер ярым хәрәкәт полосасын чикләү);

1.1.14. 2026 елның 26 июлендә 03:30 сәгатьтән 16:15 сәгатькә кадәр С.Хәким урамы буйлап (Декабристлар урамыннан Ф.Әмирхан урамына кадәр, хәрәкәтнең ике юнәлешен дә туктатып тору);

1.2. Казан шәһәре Башкарма комитетының Физик культура һәм спорт комитетына (Л.З.Гарипов) әлеге чараны әзерләүдә һәм уздыруда ярдәм күрсәтергә;

1.3. Казан шәһәре Башкарма комитетының Транспорт комитетына (А.В.Сидоров):

1.3.1. транспорт предприятиеләренә юлларны ябу һәм җәмәгать транспорты маршрутлары үзгәрү турында хәбәр итәргә;

1.3.2. ярышлар маршруты буенча юл билгеләрен урнаштыруда, сүтүдә, каплауда һәм ачуда ярдәм итәргә;

1.3.3. халыкка мәгълүмат җиткерү өчен троллейбусларның контакт челтәре терәкләрендә юлларны ябу схемаларын урнаштыруны килештерергә;

1.3.4. транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләү турында мәгълүматны Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының Интернет челтәрендә Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасы рәсми порталы» дәүләт мәгълүмат системасы составына керә торган рәсми сайтында урнаштырырга;

1.3.5. кыска вакытлы аренда хезмәте күрсәтә торган электр самокатлары (WHOOSH һәм МТС.URENT) һәм велосипедлар («Яшел шәһәр») операторлары белән берлектә 2026 елның 25 июлендә 00.00 сәгатьтән 2026 елның 26 июлендә 17.00 сәгатькә кадәр әлеге карарның 1.1 пунктчасында күрсәтелгән участокларда, марафонны оештыруда ярдәм күрсәтү максатларында файдаланудан тыш, шәхси мобильлек чараларын куеп торуны һәм аларның хәрәкәтен тыю буенча эшне оештырырга;

1.4. Казан шәһәре Башкарма комитетының Тышкы төзекләндерү комитетына (А.М.Шайнуров):

1.4.1. ярышлар маршруты буенча ремонт-төзелеш эшләрен үткәрү графигына төзәтмәләр кертергә, ярышларны әзерләгәндә килү юлларын һәм транспорт кую урыннарын төзекләндерү буенча комплекслы чаралар үткәрергә, чара тәмамланганнан соң, аны уздыру урыннары янәшәсендәге урам-юл челтәре объектларын җыештыруны тәэмин итәргә, халыкка мәгълүмат җиткерү өчен юлларны ябу схемаларын яктырту баганаларында урнаштыруны килештерергә;

1.4.2. Казан шәһәре Башкарма комитетының Торак-коммуналь хуҗалык комитеты (И.М.Хисмәтуллин) һәм Казан шәһәре Башкарма комитетының

Транспорт комитеты (А.В.Сидоров) белән берлектә әлеге карарга 1-4 номерлы кушымталар нигезендә Казан шәһәре Башкарма комитетының районнар администрацияләре белән берлектә юлларны йөк техникасы, автобуслар һәм троллейбуслар белән ябуда ярдәм күрсәтүне оештырырга;

1.5. әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

**2. Тәкъдим итәм:**

2.1. Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Казан шәһәре буенча идарәсенә (Р.Д.Габитов) әлеге чараны әзерләү һәм уздыру урыннарында җәмәгать тәртибен саклауны оештырырга, Казан шәһәре урам-юл челтәренең югарыда күрсәтелгән участокларында транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләү чорында юл хәрәкәте куркынычсызлыгы үтәлешен контрольдә тотуны тәэмин итәргә;

2.2. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Казан шәһәре буенча Сәламәтлек саклау идарәсенә (И.М.Әхмәдиев) әлеге чарада катнашучыларга медицина хезмәте күрсәтүне тәэмин итәргә;

2.3. Казан шәһәре Думасы аппаратының Мәгълүмат-аналитика идарәсенә (В.А.Казанцев) әлеге чараны әзерләү һәм уздыру чорында күрсәтелгән участокларда транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләүне кертү турында массакүләм мәгълүмат чаралары аша хәбәр итәргә.


3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары И.С.Шакировка **йөклим**.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре Башкарма комитетының
2026 елның 20 июлендәге 2543номерлы карарына
1 номерлы кушымта



Казан шәһәре Башкарма комитетының
2026 елның 20 июлендәге 2543номерлы карарына
2 номерлы кушымта



Казан шәһәре Башкарма комитетының
2026 елның 20 июлендәге 2543номерлы карарына
3 номерлы кушымта



Казан шәһәре Башкарма комитетының
2026 елның 20 июлендәге 2543номерлы карарына
4 номерлы кушымта

Ябу өчен кулланылган техника саны – 81.

Дистанциядә катнашучыларның иминлеген тәэмин итүче контролер-күрсәтүчеләр (стюардлар) саны – 90.

Дистанциядә катнашучыларның навигациясен тәэмин итүче судьялар саны  – 50.

